Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
“Олы Кавал “Чишмэкей”
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_________ Г.Г.Гимадиева

**КВН**

**Тема: “Гаилә – тормыш нигезе”**

**Максат: :** Гаилә турында тулы төшенчә бирү
**Катнашучылар**: Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче, әти-әниләр

**Үстерү бурычлар**: Балаларны ата-аналарга карата игътибарлы булырга, аларны ихтирам итәргә өйрәтү, гаиләләр белән танышу.

**Белем бирү бурычлары:** Ата-ананың кайгыртучанлыгын аңларга, тыңлаучан булырга өйрәтү

**Тәрбия бурычлары:** Ата-аналарга карата кадер-хөрмәт, ярату хисе ,өлкәннәргә карата миһербанлылык тәрбияләү

**Җиһазлау**: проигрыватель – музыка уйнаткыч, диск, мәкальләр язылган плакатлар, өстәл, урындык, шарлар. “ Гаилә - ул ил терәге!”, “ Гаилә-тормыш нигезе” дигән мәкальләр.

**Көтелгән нәтиҗә**: Балаларда матур сөйләмгә мәхәббәт уяту, сәнгатьле сөйләм формалаштыру

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_________Г.Г.Гимадиева

**Тема: Каз өмәсе-авыл бизәге**

Социаль-шәхси үсеш,танып –белү үсеше, сөйләм телен үсеше.нәфис-нәфәсәти үсеш.

**Максат** Балаларны татар халкыбызның йола бәйрәме-каз өмәсе белән таныштыру. Гореф –гадәтләргә, йолаларга карата кызыксыну,хөрмәт уяту. Сөйләм телен үстерү һәм ныгыту, өлкәннәргә карата хөрмәт тәрбияләү, үз-ара аралашу культурасын тәрбияләү, милли уеннарга , җырларга кызыксыну уяту.

**Бәйрәмне үткәрү урынын җиһазлау**:

- казлар (яки аккошлар)сурәтләнгән рәсемнәр;
- каз түшкәләре (бутафория);
- авыл өе имитациясе: өстәл, мич комган .

**Катнашучыларның атрибутлары:**

- милли кием һәм аяк киеме;
- чигелгән сөлгеләр.

**Катнашучылар**: Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче, әти-әниләр

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмәкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей" балалар бакчасы МББМБУ мөдире
_______Г.Г.Гимадиева

**ТЕМА: Хезмәт кешесен зурлыйбыз. Пешекче-җаваплы һөнәр**

**Проект төре:** информацион
**Проектның дәвамлылыгы**: Октябрь-ноябрь
**Белем бирү өлеше**: социаль-коммуникатив үсеш.
**Төп эшчәнлек:** белем бирү
**Интеграция өлеше**: сөйләм үстерү, физик үсеш, танып-белү.
**Тормышка ашыру формасы**: төркемләп.
**Проектта катнашучылар**: тәрбияче,кече тәрбияче, пешекче, китапханәче,
3-6яшьлек балалар, төркемнең әти-әниләре.
**Проект эшчәнлегенең максаты**: максатчан эшчәнлек аша 3-6 яшьлек балаларның һәр һөнәрнең мөһимлеге турында күзаллауларын булдыру, пешекче һөнәре белән таныштыру, белемнәрне системалаштыру һәм хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү.
**Проект эшчәнлегенең бурычлары:**
балаларны пешекче һөнәрләре белән таныштыру;
-һәр кеше тормышында хезмәтнең әһәмияте турында аңлату;
-коммуникатив күнекмәләрен үстерү;
-бу тема буенча сүзлек запасын арттыру;
-күреп истә калдыру сәләтләрен үстерү, игътибарлылык тәрбияләү;
-өлкәннәр хезмәтенә, эш нәтиҗәләренә сакчыл караш булдыру.
**Көтеләчәк нәтиҗәләр:**
**Балалар өчен:**
-пешекче һөнәре турында белемнәрне киңәйтү;
-пешекче хезмәтендәге кирәк-яракларны белү;
- үзара аралашуын күрсәтү;
-өлкәннәрнең хезмәтендә хәлләреннән килгәнче катнашу;
-хезмәткә уңай караш.
**Әти-әниләр өчен:**
- балаларның яшьтән һөнәри юнәлеш алулары турында белемнәрен киңәйтү;
- проект эше белән канәгать булу.
**Педагоглар өчен:**
- мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яшьтән һөнәри юнәлеш алулары турында белемнәрен ныгыту;
-дидактик уеннар туплау, сюжетлы-рольле уеннар өчен атрибутлар ясау.
**Проект эшчәнлегенең этаплары:**
**1.Информацион-мотивацияле.**
**Әзерлек эше:**

-тема буенча тиешле әдәбият туплау, проектның темасы, аның зарурилыгын нигезләү, максаты һәм бурычларын кую;
-планлаштыру.
- дидактик уеннар табу, тема буенча күргәзмә һәм информацион әсбаплар җыю.
- эти-әниләр өчен консультацияләр әзерләү, индивидуаль әңгәмәләр оештыру, аларны дидактик уеннар туплауга, сюжетлы-рольле уеннар өчен атрибутлар ясауга тарту.
-Әти-әниләр өчен анкеталаштыру . Тема."Балаларны төрле һөнәр иясләре белән кызыксындыруда гаиләнең әһәмияте"

**2.Практик этап.**

1.Эшчәнлекләр, әңгәмәләр, ашханәгә экскурсия үткәрү
Максат: Пешекче һөнәре белән таныштыру, хезмәт процессы һәм кирәкле ярдәмче предметларны ачыклау. Савыт-саба турында белемнәрен киңәйтү. Пешекче һөнәренә кызыксыну, ихтирамлы караш тәрбияләү
2.Дидактик уен "Аш яисә компот"
Максат: балаларның җиләк-җимешләр һәм яшелчәләр турында белемнәрен арттыру.
3.Бармак гимнастикасы "Кәбестә", "Компот"
Максат: кул моторикасын үстерү, сәнгатьле сөйләмгә өндәү.
4.Матур әдәбият әсәрләре уку:
К.Чуковский "Федорның кайгысы"
Максат: балаларны әкият тыңларга, игътибарлы булырга өйрәтү, сөйләүченең сәнгатьле сөйләменә игътибарларын юнәлтү. Савыт-саба, җиләк-җимешләр һәм яшелчәләр турында табышмаклар әйтү.
5.Сюжетлы-рольле уен "Курчакка төшке аш әзерлибез".
Максат: әйләнә-тирә тормыш турында уеннар уйнарга омтылыш уяту.
6.Консультация "Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга яшьтән һөнәри юнәлеш бирү"
7.Буклет ясау "Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга хезмәт тәрбиясе бирүнең асылы". "Балаларда хезмәт сөючәнлек тәрбияләү"
8. Муниципаль бәйгедә катнашу.

**3 .Гомумиләштерү этабы**

1.Күңел ачу кичәсе "Ягез әле пешекчеләр", "Һөнәр кеше канаты, канатлы бул, канатлы!
2.Фотокүргәзмә "Әти-әниемнең һөнәрләре"
3.Проектны презентацияләү.
4.Проектның нәтиҗәләре:
-балаларның һөнәрләр турында белемнәре киңәйде.
-балалар һөнәрләрне атарга өйрәнделәр, һөнәр ияләренә хөрмәт артты ;
-пешекче һөнәренә кызыксынулары артты;
-төп хезмәт хәрәкәтләре, эш кирәк-яраклары белән таныштылар.
-шигырьләр, табышмаклар уку һәм бармак уеннары нигезендә сүз байлыклары артты.
-мөстәкыйль уеннарда үзара яхшы аралаша башладылар.
-өлкәннәр хезмәтенә уңай караш сизелде.
-тәрбиячеләр һәм эти-әниләр бердәмлек күрсәттеләр.
Проектның максатына ирешелгән, бурычлары үтәлгән диеп санарга мөмкин.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_____________Г.Г.Гимадиева

**Тем: Үткәнәрне барыйбыз, киләчәккә атлыйбыз**

**1.Кереш өлеш**

"Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк" дигән мәкальнең нәкъ менә хәзерге чорда аеруча актуаль яңгырый. Көннәр,еллар егәнсез аргамактан ыргылып алга чаба. Кайвакыт үткәнне түгел, бүгегесен уйларга, анализларга, нәрсәгәдер тотынып эшләргә вакыт җитми сыман.Бу шулай... Ләкин килә шундый бер көн. Бөтен уйларың , фикерләрен үткәнне барлауга ниндидер ачышлар ясарга юнәлә.Безнең халыкның тарихы, мәдәнияте искиткеч бай булган.Моның бөтенесен еллар шаукымыннан елып калырга, түкми-чәчми киләчәк буынга тапшыру-хәзерге буынның иң зур бурычы.Татар халкы арасында да зыялы, укымышлы мәгърифәтле асыл затлар күп булган.Авыр караңгы елларда да халыкны киләчәккә өмет, күңелләрендәге иман нурын саклап калган.

**Минем максатым**. Балалар үткәнне белсеннәр, михербан-шәфкатьле, үз телләрен , илен яратучылар булып үссеннәр дип тырышам.

**Катнашучылар:** Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче, әти-әниләр

**Көтелгән нәтиҗә:** Балаларда матур сөйләмгә, туган телгә, илгә мәхәббәт, үткәннәргә, киләчәккә хөрмәт уяту, сәнгатьле сөйләм формалаштыру,

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
______________ Г.Г.Гимадиева

**Әти-әниләр катнашында интеграль ачык эшчәнлек**

**Тема: Гаилә-имин юл күрсәтүче**!

**Максат** Әти-әниләр, балалалар,мәктәп укучылары катнашында юл йөрү кагыйдәләре, юл билгеләре, яктырткыч элементлар, саклык каешы турында белемнәрне тикшерү һәм ныгыту;

-Юл йөрү кагыйдәләрен пропагандалау;

-Ярдәмчеллек, иптәшлек хисе тәрбияләү

**Бурычлар.**

**Белем бирү бурычлары:** Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү, кабатлау, ныгыту.

**Үстерү бурычлары**: Игътибарлылык, кабул итү, хәтерне сәләтен үстерү.

**Тәрбияви бурычлар**: Үзара дуслык, ярдәмләшү хисләрен тәрбияләү, юлда үзеңне дөрес тоту культурасын тәрбияләү. Юл йөрү кагыйдәләренә ихтирам тәрбияләү.

**Катнашучылар**. Әти-әниләр, балалар, мәктәп укучылары, тәрбияче, кече тәрбияче.

Әзерлек эшләре. Эшчәнлек өчен уен атрибутлары әзерләү, фликерлар алу.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
“Олы Кавал “Чишмэкей”
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
____________ Г.Г.Гимадиева

**Тема: “Милли тәрбия бирүдә Габдулла Тукай иҗатын куллану”**
**(Ата-аналарга күрсәтү өчен ачык эшчәнлек)**

**Эшчәнлекнең актуальлеге:**
“Габдулла Тукай иҗаты буенча сәяхәт” проекты балаларны, әти-әниләрне, тәрбиячеләрне аның иҗаты белән тирәнтен таныштыруга, аларның укуга теләген уятуга юнәлдерелгән.
Габдулла Тукайның әсәрләре туган якка, аның табигатенә мәхәббәт уята, иҗаты туган йортына, туган җиренә игътибарлы сакчыл караш тәрбияли, башлаган эшне азакка чаклы җиткерергә теләк, түземлелек үстерә һәм эстетик тәрбия бирә. Габдулла Тукайның шигырьләре һәм әкиятләре аркылы бала әйләнә-тирә мохит белән таныша. Габдулла Тукай әсәрләре аша балалар татар халкының гореф-гадәтләре белән таныша ала, һәм олыларга карата кайгыртучанлык, игътибар һәм ихтирам хисләрен, балаларда эшчәнлек, гаделлек, батырлык, тыйнаклык, җаваплылык, белем алуга омтылыш тәрбияли, үз телең – ана теленең биеклеген белеп яшәргә һәм аны өйрәнүне һәрвакыт дәвам итәргә кирәклеген төшендерә
**Эшчәнлектә катнашучылар**: балалар, әти-әниләр, тәрбиячеләр, китапханәче .
**Төп белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше,нәфис-нәфасәти,танып-белү,социаль-шәхси,физик үсеш.
**Максат:** Габдулла Тукай иҗаты белән таныштыруның әһәмиятен үстерү.
**Бурычлар:**
1.Тәрбияви:балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту,ихтирам хисләре тәрбияләү,әкиятләр аша әхлак тәрбиясе бирү.
2.Үстерешле:балаларның әдәби әсәрләрне тыңлый һәм аңлый белү сәләтен ,эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирә белү күнекмәләрен үстерү.
3.Өйрәтү:укылган әсәрләрнең эчтәлеген аңлап,анда катнашучыларның үз-үзләрен тотышларына бәя бирергә өйрәтү.
**Көтелгән нәтиҗәләр:**
Балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну артты.
Балалар үз-үзләрен сәхнәдә тотарга өйрәнде, балаларда Г.Тукай әкиятләрендәге геройларга охшарга теләк туды.
Әти-әниләр белән тыгыз элемтә туды.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.